# Туган тел дәресләрендә критик фикерләү технологиясе ысулларын куллану

Алабуга шәһәре 1 нче урта мәктәбенең 1 нче квалификацион категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы: Садыкова Гөлсинә Минзариф кызы.

# Максатлары:

1) укучыларның интеллектуаль фикерләү сәләтләрен үстерү;

2) танып-белү эшчәнлеген үстерүгә юнәлтелгән күнекмәләр булдыру һәм продуктив иҗат югарылыгына күтәрелергә ярдәм итү.

# Бурычлары:

1)укучы һәм укытучы арасында иҗади хезмәттәшлек булдыру; укучыны креатив эшчәнлеккә тарту;

2) белем бирү процессын оптимальләштерү, белем алуга уңай омтылыш (мотивация) булдыру.

# Критик фикерләү технологиясенә корылган дәрес **өч этаптан** тора:

өйрәнелә торган темага кызыксыну уяту → төшенү (аңлау) → рефлексия.

# Кызыксыну этабы

Кызыксыну уяту һәр дәрестә була. Бу өйрәнелә торган тема яки проблема буенча укучының элекке белемнәрен актуальләштерү һәм гомумиләштерү һәм актив эшчәнлеккә (уку эшчәнлегенә) ныклы кызыксыну уяту өчен кирәк.

# Төшенү (аңлау) этабы

Укучы өйрәнелә торган материал буенча яңа мәгълүмат ала, төшенчәләрне, фактларны аңлап, элегрәк алган белемнәрен яңалары белән бәйли, тулыландыра.

# Рефлексия этабы

Укучы өйрәнгәннәрне бербөтен итеп күзаллый, аңлап гомумиләштерә, яңа мәгълүматны тулысынча үзләштерә, иҗади фикер йөртә һәм өйрәнелә торган материалга карата аның шәхси мөнәсәбәте формалаша.

Критик фикерләү технологиясенең **төрле ысуллары** бар:

“Идеяләр кәрзине” , “ Инсерт, “Синквейн”, “Кластер”, ”Блум ромашкасы”, “Алты эшләпә” һ.б.

# Идеяләр кәрзине



**Исем предметны белдерә**

**Исем кем? нәрсә? сорауларын җавап бирә**

**Исемнәр килеш белән төрләнәләр**

**Исем мөстәкыйль сүз төркеме**

**Исемнәр ялгызлык һәм уртаклык була**

**Исемнәр берлек һәм күплек саннарда килә**

# Инсерт ысулы

∨ *(галочка)* тамгасын укучы тексттагы мәгълүмат белән күптәннән таныш булган очракта куя. Ул моны белә.

\+ *(плюс)* тамгасын укучы үзенә таныш булмаган яңа мәгълүматны очратканда куеп бара.

– *(минус)* тамгасын укучы текстта очраган мәгълүматның үзе моңарчы беләм дип йөргән фикер белән туры килмәвен күргәч куя.

**?** *(сорау)* тамгасы белән укучы таныш булмаган мәгълүматны билгели. Ул моны белергә теләвен күрсәтә.

# Нәрсә соң ул синквейн?

Бала һәр дәрескә теләк белән килсен өчен, аңарда соклану
һәм кәнәгатьләнү тойгылары уятырга,
аны файдалы һәм максатка юнәлешле эшчәнлеккә сиздерми
җәлеп итәрлек эш формалары тәкъдим итәргә кирәк.
Менә шундый эш төрләренең берсе ул **синквейн.**

**Синквейн-**
француз теленнән кергән сүз, 5 дигәнне аңлата.
Ул шигъри формада язылган кыска әдәби әсәр,
билгеле план буенча языла,
биш юлдан тора, предметны ( төшенчәне) ачыклый.






**Исем (термин)**

**Сыйфат + сыйфат**

**Фигыль + фигыль + фигыль**

**Җөмлә (фраза)**

**Сүз (нәтиҗә)**

**Укытучы**

**Иҗади, ачык күңелле.**

**Укыта, тәрбияли, иҗат итә.**

**Планнары күп – вакыт аз.**

**Изге һөнәр**

**Габдулла Тукай**

**Бөек, моңлы**

**Иҗат итә, яза, эшли**

**Милләткә хезмәт итә.**

**Даһи шагыйрь**

# Критик фикерләү технологиясе буларак “кластер” алымы

**Кластер** - уку материалын график сызым ярдәмендә системалаштыру алымы.

Универсаль алым, аны дәреснең һәр стадиясендә кулланырга мөмкин:

1 нче стадия: кызыксындыру

(белем - күнекмәләрне тәртипкә китерү)

2 нче стадия: аңлау, төшенү (яңалыкны теркәп кую)

3 нче стадия: рефлексия (фаразланган ялгыш раслауларны төзәтү)

# “Блум ромашкасы” алымы



# “Алты эшләпә” ысулы













“Алты эшләпә” ысулын Британия психологы Эдвард де Боно уйлап тапкан.

Бу ысул ярдәмендә фикерләүнең алты төрен күрсәтергә була.

Критик фикерләүнең бу ысулы ярдәмендә укучылар укылган әсәргә уен формасында тирәнтен анализ ясыйлар. Алар дүртәр кешелек алты төркемгә бүленәләр. Һәр төркемгә төрле төстәге эшләпә бирелә. Нинди төстәге эшләпә алуга карап, укучылар укылган әсәр буенча геройларга карата үз фикерләрен белдерәләр, проблемаларны анализлыйлар, нәтиҗәләр чыгаралар. Төркемнән бер кеше барысы исеменнән чыгыш ясый.

**Ак эшләпә.** Укучы бары тик фактлар белән генә эшли.

**Кара эшләпә.** Вакыйгаларның тискәре яклары сөйләнелә.


**Сары эшләпә.** Бары тик уңай фикерләр генә әйтелә.

**Кызыл эшләпә.** Эмоциональ фикерләүне таләп итә.

**Яшел эшләпә.** Иҗади фикерләү, фаразлар.

**Зәңгәр эшләпә.** Фикерләрне гомумиләштерү, йомгаклау, нәтиҗә чыгару.






Нинди яңа мәгълүмат белдегез?
Фактлар



Өйрәнгән мәгълүматның уңай яклары. Позитив фикерләр



Нинди тискәре яклар күренде?
Тәнкыйть күзлегеннән карау



Сездә нинди хисләр туды?
Эмоциональ кабул итү



Иҗади фикерләү.
Фаразлар



Фикерләрне гомумиләштерү.
Йомгаклау, нәтиҗә ясау

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!